ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2018 Казан ш. № 10-69/кс

Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга 2019 елга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 10-69/кс
карарының кушымтасы

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга календарь бүленеш белән тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга билгеләнгән тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Ташландык суны чыгаруга билгеләнгән тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Миннебай-ТКХ» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 17,21 | 17,62 | | |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| | Чистай муниципаль районы | | | | |
| 2 | «Чистай авыл торак-коммуналь хуҗалыгы» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 37,18 | 38,60 | 10,46 | 10,46 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге